**Важашур авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

28 январь 2022 ел № 1

Важашур авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 февральенда 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Важашур авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Важашур авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 февральенда 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә, 18.1 статьясын түбәндәге нигездә бәян итеп, (Важашур авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 34 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 14 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 4 номерлы, 2019 елның 29 августындагы 13 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәрешләр кертергә:

«18. 1. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең максималь күләме– 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы П.Л.Иванов

ОГРН 1021607752770
ИНН 1623001734